**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# РЕШЕНИЕ

IV чакырылышның XIX утырышы

«05» июль 2024 ел № 16 ш.т. Урыссу б.

2025 елга һәм 2026, 2027 елларның план чорына физик затлар керемenә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына өстәмә түләүләр нормативы белән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне алыштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 маддәсендәге 5 пункты, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. 2025 елга һәм 2026, 2027 елларның план чорына физик затлар керемenә салымнан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетына өстәмә түләүләр нормативы белән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне алыштыруны килештерергә.

2. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы-
Татарстан Республикасы
Ютазы районы Сорветы рәисе А.Ә.Шафигуллин